**СОВЕТ ЧИРПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422615, с. Чирпы,
ул. Заводская, д.22
тел: 2-91-45

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧИРПЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422615, Чирпы авылы,
Завод урамы, 22 йорт,
тел: 2-91-45

**2024 елның «18» октябре** **47 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 35 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 35 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.2. 1 пунктның 1.2 һәм 1.3 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« торак-коммуналь комплексының торак фонды һәм (яисә) инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегеннән тыш) торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына кагылмый торган яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге пунктчада күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш, җир кишәрлекләренә карата 0,3 %,”»;

1.3 «бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган шәхси ярдәмче хуҗалыкта, шулай ук "Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата, моңа әлеге пунктчада күрсәтелгән һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләре керми, 0,3 %»;

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Чирпы**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Зотин Р. Ю.**